БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 5 » июль 2018 ел № 243

**Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 28 августындагы 1316 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 18 июнендәге 3680/12 номерлы, 3681/12 номерлы, 3683/12 номерлы, 2012 елның 21 июнендәге 3790/12 номерлы, 2012 елның 22 июнендәге 3873/12 номерлы, 3844/12 номерлы, 3845/12 номерлы, 2012 елның 27 июнендәге 3938/12 номерлы, 3939/12 номерлы, 3940/12 номерлы боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Карамактагыларны стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына стационар хезмәтләр күрсәтүгә җибәрү турында карарлар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Опека яки попечительлек билгеләү яисә суд тәртибендә хокукый сәләтсез яки хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булмаган затка опека яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Карамактагы бала мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Балигъ булмаган хокукый сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә опекунга торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Опекунга опекага алынган баланыкы булган торакны наемга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Карамактагыланың мөлкәте белән алыш-бирешләргә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Яшәү урынын алмаштыруга бәйле рәвештә опекунга карамактагы затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

1.8. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

1.9. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).

1.10. стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда булган хокукый сәләтсез гражданнарны вакытлыча Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга тапшыру турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта).

1.11. Ятим балалар өчен оешмаларда булган балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булмаган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (11 нче кушымта).

1.12. Балигъ булмаган (булмананнар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (12 нче кушымта).

1.13. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (13 нче кушымта).

1.14. Балигъ булмаганнарның күчмә милкен тартып алу буенча алыш-бирешләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (14 нче кушымта).

1.15. Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (15 нче кушымта).

1.16. Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар тарафыннан опека (попечительлек) билгеләү (түләүле яки түләүсез нигездә) яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (16 нчы кушымта).

1.17. Балигъ булмаганны эмансипацияләү (балигъ булмаганны тулысынча хокукый сәләтле дип игълан итү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (17 нче кушымта).

1.18. Балигъ булмаган баанықы булган күчемсез мөлкәтне тартып алу буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (18 нче кушымта).

1.19. Балигъ булмаганнар катнашында кредит акчаларын кулланып торак

сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (19 нчы кушымта).

1.20. Законлы вәкилгә балигъ булмаганнарның акчалата кертемен алу өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (20 нче кушымта).

1.21. Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга баланы (балаларны) тәрбияләп торганга акча билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга тиешле акчалата бүләкләүне түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (21 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р.И. Шакиров